


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№4 Декабрь, 2024 ел*




## Яңа ел килә

**Беренче карашка, елның иң могҗизалы ва - кыйгасы турында инде бөтен әйберне дә белеп бетергәнбез кебек. Әмма Яңа ел турында без хәтта уйлап та карамаган фактлар бар икән бит, дуслар. Шуларның унысы белән язмада бүлештек.**

1. Урта гасыр Ауропада чыршыны аскы ягын түшәмгә беркетеп элгәннәр. Ни өченме? Болай гына, кәеф кәтәренкелеге өчен. Яңа елны могҗизалар һәм бераз сәерлекләр төне итеп кабул иткәннәр.
2. Беренче электр гирляндасы эленгән чыршы 1895 елда кабызыла. Ул Ак йортта, АКШ президенты резиденциясе алдында куелган була.
3. Белгәнегезчә, барлык Кыш бабайлар да бүләкләр китерә, ләкин төрле илдәгесе – төрлечә. Әйтик, чыршы астында бүләкне Россия Кыш Бабае калдыра. Оек эчендә бүләкләрне – инглизләр һәм ирландлар, ә итектә мексиканнар таба. Франциядә Яңа ел бүләкләре төтен морҗасы аша төшә, ә Испаниядә алар балконда көтә. Швециядә исә Кыш бабай бүләкләрне мичкә сала, ә Германиядә тәрәзә төбендә калдыра.
4. Санта Клаусның хатыны бар. Аны Миссис Санта-Клаус дип йөртәләр.
5. Безнең Кыш бабайның туган көне – 18 ноябрь. Кыш бабайга төгәл генә ничә яшь булуын беркем белми, әмма китап битләрендә ул беренче тапкыр 1840 елда пәйда була.
6. Кыш бабай өйгә бүләкләр белән Яңа ел бәйрәм ителә башлаганнан бирле килә. Элек ул бүләкләрен тәртипле балаларга гына тапшырган, ә шук һәм тыңламаганнарны таяк белән кыйнаган.
7. Яңа ел төнендә теләнгән теләкләрнең 30%ы гына чынга аша.
8. Россиялеләр оекны (носки) иң начар бүләк дип саный.
9. 30 декабрьдән 31 декабрьгә каршы төндә күрәзә, хак төшләр керә. Шуңа ул төшне исеңдә калдырырга тырыш.
10. Россиядә беренче бәйрәм чыршылары фонарьлар, гирляндалар, алмалар һәм конфетлар белән бизәлә торган булган.

**7 нче сыйныф укучысы Заһидуллина Рәзинә**



## Кышкы шөгыльләр

Кыш житүне кем генә яратмый икән аны. Мәсәлән, мин үзем дә кыш фасылын аерым яратам. Саф һавада төрле уеннар уйнавы үзе бер рәхәт һәм файдалы.

Мин Әтнә районы Күәм авылында укыйм. Безнең үзебезнең хоккей мәйданчыгы бар. Дәресләр тәмамланганнан соң без сыйныфташларыбыз белән шул бозда рәхәтләнеп тимераякта шуабыз. Без анда ярышлар да уздырабыз. Минем иң яраткан уеным тимераякта шуу. Шулай ук дуслар белән кар атырга һәм чанада шуарга яратам.

Кыш көне кар бабай ясау, кар чистарту, кар атышу, чана, чаңгы шуу кебек төрле уеннар уйлап табарга була. Ә ял көннәрендә без әти-әниләр белән шугалакка йөрибез. Анда гаилә белән рәхәтләнеп уйныйбыз, ял итәбез.

Кыш - күңелле кар уеннары һәм күңел ачулар чоры. Шуңа күрә ул миңа елдан ел күбрәк ошый

**4 нче сыйныф укучысы Гәрәева Зилия**

## Кыш

Бүген чыктык урамга
Чана-чаңгы шуарга.
Көн дә бик салкын иде,
Безнең шуасы килде.
Әй шудык без, әй шудык
Таудан егылып төштек.
Салкын безнең битләрне,
Кызартты да агартты.

**2 сыйныф укучысы Галәвиев Ранил**

## Салкын кыш.

Салкын кыш килде
Агачларга бәс элде.
Болыннарга юрган япты,
Безне җылы киендерде.
Чаналар тагып
Барабыз тауга.
Кар атышып, уйныйбыз анда.
Өйгә кайттык исә
Битләр кызара
Киемнән тып-тып
Тамчылар тама.

**2 класс укучысы Василов Азат**

## Кадерле әбием



Гаилә елы уңаеннан, гаиләдәге өлкәннәр, аларның балачагы ничек узган дигән темага инша яздык. Минем әбием - Суфия исемле. Ул - Куәм авылында туып үскән. Әбием үзенең балачагын бик сагынып, искә алып сөйли. Телефонсыз, рәхәт вакытлар иде ди ул. Әбием сигезъеллык Куәм мәктәбендә белем алган, башлангычта Сәгыева Йолдыз апа укыткан. 5-8 нче класларда сыйныф җитәкчесе Фәизов Фәргат абый булган. 9 нчы классны Әтнә урта мәктәбендә укыган. 10-11 нче классны Куәмдә кичке мәктәптә тәмамлаган. Көндезләрен фермада эшләгән, кичләрен мәктәптә укыган. “Чүрәкәй”, “Качышлы” уйный идек, кышын тау шуганнар, җәйләрен су коенганнар, җиләккә барганнар. Кул эшләре эшләп, шәл бәйләгәннәр, әдәби китаплар укыганнар, ә китапханәдә Гатауллина Сания апай эшләгән ул чорда. “Өйдәге эшләргә гел булыштык, бергәләп каз бәпкәләре сакладык, көтү каршына барып, хайваннарны барлап алып кайта идек”,- дип сөйли әбием. “Фермага барып, әнигә булыша идем” дип тә куя. Капка төпләрендә кич утырулары да истә калган. Әбием дус кызлары турында да искә алды. Әбием сөйләгән хәтирәләр, аның өчен кадерле.

**5 нче сыйныф укучысы Нәҗмиев Риназ**

## Хәтер гомерлек...



Минем карт бабаем – Галимуллин Газимҗан Галимулла улы. 12 нче декабрь – илебезне саклаучы батырлар көне. Аның турында язмый калсам ярамас кебек.

Ул 9 сентябрьнең 1923 нче елында Дусым авылында дөньяга килә.

Карт бабайны 1942 нче елның 1 нче маенда сугышка алалар, аны Ленинград шәһәренә җибәрәләр.

1942 нче елның 18 нче августында тревога игълан ителә, барлык солдатларны да алгы сызыкка чыгаралар, аларның бер кулларында винтовка, икенчесендә көрәк була. Бу сугышта карт бабайның күзенә граната кыйпылчыгы эләгеп нык яралана. Аны Ленинградск госпиталендә дәвалыйлар. Госпитальдән чыккач карт бабай кабаттан сугышка керә.

1943 нче елда фронтның беренче линиясен фашист баскыннарыннан азатиткәч, карт бабай яңадан снаряд кыйпылчыгы белән яралана, рәтләнгәч ул кабаттан сугыш кырына әйләнеп кайта, минем карт бабаем әйтә торган булган: “Без Ватан өчен, балалар һәм аналар өчен алга бардык, чигенергә ярамый иде”.

Тиздән карт бабайны, сугышка Япониягә җибәрәләр. Авылга ул 1947 нче елның 8 нче мартында гына әйләнеп кайта ала.

Бөек Ватан сугышында катнашкан өчен карт бабаемны бик күп медальләр белән бүләклиләр. Иң истәлекләре булып карт бабаем өчен: “Ленинград оборонасы өчен”, “Сугышчан казанышлары өчен”, “Японияне җиңгән өчен”, “Сталиннан рәхмәт хаты” булып тора.

Кызганычка каршы минем карт бабаем күптән мәрхүм булган, мин аны үзем хәтерләмим, аның турындагы истәлекләрне мин әбием һәм әнием сөйләве буенча беләм, мин карт бабаем белән горурланам!

**5 нче сыйныф укучысы Нәҗмиев Риназ**

## 12 декабрь – Россия Федерациясе Конституциясе кабул ителгән көн



12 нче декабрь – Россия Федерациясе Конституциясе көне буларак билгеләп үтелә. Быел илебезнең бу төп законы кабул ителүгә 31 ел. Шул уңайдан мәктәбебездә тематик сыйныф сәгатьләре узды. 9 һәм 10-11 нче сыйныф укучылары арасында Россия Федерациясе Конституциясе буенча белемнәрне барлап ярыш үткәрелде. Һәр команда да бик матур уен күрсәттеләр. Мин аларга карап сокландым. Конституцияне барыбыз да укыйк, хөрмәт итик, белик!

**6 нчы сыйныф укучысы Халикова Фирүзә**

## Яраткан китабым

Мин китап укырга бик яратам. Бу атнада китапханәдән Роберт Миңнуллинның «Кунакка килегез” дигән китабын алдым. Мин китаптагы барлык шигырьләрне дә укыдым. Аеруча шагыйрьнең “Мин әгәр икәү булсам”дигән шигырен яратып укыдым. Аның барлык шигырьләре дә бик кызык. Миңа Роберт Миңнуллинның “Кунакка килегез” дигән китабы бик ошады.

**3нче сыйныф укучысы Халитова Иркә**

## Китап укыгыз!

Мин китапханәдән китаплар алып укырга бик яратам. Абдулла Алишның ”Сертотмас үрдәк” әкиятен укыдым. Миңа бер китап бигрәк тә ошады. Ул китап “Весёлый урок” дип атала.

Китапларны ешрак укырга һәм саклап тотарга кирәк дип уйлыйм.

**3нче сыйныф укучысы Юсупова Динә**